ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

23 05 2023 г. № 460

2023 елга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләрендә торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясының 4 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясының 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар, торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын ачыклау тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урын милекчеләре өчен, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгының 4.1 пунктына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2023 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләрендә күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын 10 процент күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН МКУ * ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ МКУ * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874